СОВЕТ ОКТЯБРЬСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ОКТЯБРЬСКИЙ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ — КАРАР

24.10.2018 пос. Октябрьский 50-217

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының
Октябрьский авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында Нигезләмәгә
үзгәрешләр кертү хакында

“Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында” 2007 елның 02 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законга үзгәрешләр кертелүгә бәйле рәвештә, Югары Ослан муниципаль районының Октябрьский авыл җирлеге Уставы нигезендә,
Югары Ослан муниципаль районының
Октябрьский авыл җирлеге Советы
карар итте:

1. 2017 елның 27 сентябрендәге 28-132 номерлы Октябрьский авыл җирлеге Советы карары белән расланган Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Октябрьский авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:
   1.1. Нигезләмәнең 7.3.3 пунктын түбәндәге эчтәлекле 2.1 пунктчасы белән тулыландырырга:

«2.1.) коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау буенча тиешле муниципаль органның кадрлар хезмәте бүлекчәсенең коррупциячел хокук бозуларны кылуның фактлагы шартлары бәян ителә торган доклады һәм муниципаль хезмәткәрне аның ризалыгы белән генә һәм коррупциячел хокук бозуны кылу фактын тану шарты белән генә язмача аңлату (ышанычны югалтуга бәйле рәвештә эштән азат итү рәвешендәге хокук бозулардан тыш);

2. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Октябрьский авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәнең текстын яңа редакциядә расларга (1 нче кушымта).

3. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.

Совет рәисе,
Югары Ослан муниципаль районының
Октябрьский авыл җирлеге башлыгы Ш.Р. Азизов